Әнисә ИБРАҺИМОВА,
11 нче шәһәр балалар
китапханәсе мөдире

# Күңелләребездә калыр якты истәлек...

Шәһәрдәшебез шагыйрь Мәхмүт Газизов белән безнең 11 нче балалар китапханәсе күп еллар дусларча һәм эшлекле мөнәсәбәттә булды. Аның безнең мәхәлләдә китапханә белән янәшәдә яшәве дә моңа этәргеч булгандыр.

Мәхмүт абый безгә, китапханәчеләргә, бик зур хөрмәт белән карый иде. Ул балаларны бик яратып, алар белән очрашуларга бик теләп йөрде. Балалар да аңа тартыла иде, чөнки Мәхмүт абыйның җылы аралашуыннан, уртак тел таба белүеннән аның зур тәҗрибәле педагог икәнлеге күренеп тора иде.

Мирас калдыра алган кеше бәхетле. Мирас ул – адәм баласының киләчәк буыннарга васыяте. Мәхмүт Газизовның китапларына сыйган шигырьләре, ул шигырьләрнең һәрбер юлы – киләчәк буыннарга васыять булып калырлык олы мирас.

Аның гап-гади генә күренгән шигырьләре аңлаешлы, саф халыкчан телдә язылганнар. Ул тормышның гыйбрәтле, көлкеле якларын эләктереп алып нечкә юморлы, фәлсәфи мәгънәле шигырьләргә әйләндерә. Мәхмүт абыйның шигырьләрендә шаянлык, тапкырлык, чын ихласлык әсир итә, үзенә бетереп ала, бала шигырь тылсымы эчендә яши башлый. Уен-көлке белән сугарылган шигырьләре күңелне күтәрә, көлдерә.

Балачак – серле бер дөнья. Мәхмүт абый да аннан аерыла алмый яшәде. Балаларның җанын, рухын үзенең гаҗәеп шигырьләре белән баетты.

Безнең китапханә Мәхмүт абыйны чакырып 35 нче мәктәпнең 2, 3, 4 нче сыйныф укучылары белән күп очрашулар үткәрде. Аның белән булган очрашуларда шагыйрь бик кызыклы итеп үзенең шаян шигырьләре белән төрле уеннар уйната иде, балалар аның шигырьләрен яттан сөйлиләр һәм үзләренең сорауларын бирәләр иде.

Бигрәк тә аның 70 еллык юбилее уңаеннан 2010 елның 15 февралендә булган очрашу күңелгә уелып калды. «Балачак – үзе бәйрәм» диеп аталган шигъри уен кичәсе иде ул. Бу кичәгә без 35 нче мәктәпнең 4 нче сыйныф укучыларын чакырдык. Уку залында Мәхмүт абыйның иҗатына багышланган зур китап күргәзмәсе оештырдык. Күргәзмәгә бездә булган китаплар гына түгел, ә шагыйрьнең үзе белән алып килгән шәхси китапханәсеннән истәлекләр, мәкаләләр җыентыгы да куелды. Кичә әңгәмә формасында барды, автор үзенең балачак хатирәләре белән аны тагын да җанландырды, кызларын, оныкларын үстерү чорында булган кызыклы хәлләрне сөйләп, шаяртып балаларда иҗатына зур кызыксыну уятты.

Мәхмүт абыйның шигырьләре белән генә танышу түгел, ә үзе белән очрашу мөмкинлеге, аңа кызыксындырган

сорауларны бирә алуыбыз, ә соңыннан чәй табынында китапханәчеләр белән чын күңелдән дустанә аралашуы – безнең күңелләрдә җылы тәэсир калдырды.

Гомумән, Мәхмүт абый, бик ачык күңелле, кешелекле һәм юмарт кеше иде. Ул үзенең гаиләсе турында да сөйләргә ярата иде, китап бастыруда спонсорлар табу җиңел түгеллеген дә яшерми иде. Безне дә игътибар белән тыңлый, төрле киңәшләрен бирә иде. Узып барышлый да ул безнең китапханәгә хәл белергә кереп чыга, ә җәй һәм көз көннәрендә үз бакчасында үстергән җимешләре белән сыйлый иде.

Бакый дөньяга күчсә дә, язган шигырьләре ул яратып яшәгән җирдә калды һәм меңнәрчә кешеләрнең йөрәгендә яшәвен дәвам итә.




